Балаң өчен җаның тыныч булсын дисәң – ТҮЛӘ

1 февральдән Казан балалар бакчаларында 12 сәгатьлек төркемнәр бетерелә. Шәһәрдәге күпчелекне тәшкил иткән төркемнәр иртәнге сәгать 7.30дан 18.00гә кадәр эшли башлаячак. Бу – төркемнең эш сәгате төгәлләнгәч, бала урамда кала дигән сүз түгел, әлбәттә. Сабыйны алтыдан соң да балалар бакчасында калдырырга була. Тик моның өчен аена 300 сум түләргә туры киләчәк.

4 БИТ

«Сулык янында патшалык ясап яшәргә телиләр»

Илсур Гыйльметдинов:

– Элек халык, су басудан куркып, судан ерак урнашырга тырышкан. Элекке йортларны карасак, су янындагылар бик аз. Хәзер модасы шундый: сулык янында биек киртә белән уратып алып, патшалык ясап яшәргә телиләр.

5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 24.01.2017 | №6 (5768)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ЧАКЫРА БЕЛЕП ЧАКЫРТЫГЫЗ

Дамир Бәдриев фотосы

Кискен тын юллары вируслы инфекциясе авырулары һәм грипп эпидемиясе вакытында ашыгыч ярдәм хезмәте чакырту, халыкка медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләсе аеруча актуаль. Быел 3 гыйнвар көнне Казанда ашыгыч ярдәм хезмәтен чакырту буенча рекорд куелган. Бер көндә 2226 чакыру кабул ителгән.

– Бәйрәм арасында көненә кискен тын юллары инфекциясе авырулары һәм грипп белән бәйле 500-600 чакыру кабул ителә иде, хәзер бу күрсәткечләр 280-300 кешегә калды. Ашыгыч ярдәм хезмәтен чакырту кимеде, – ди Татарстанның ашыгыч ярдәм хезмәте баш белгече Марина Воронцова.

Моңа карап, кизү кире чигенә, дип тә нәтиҗә ясап булмый. Хәер, авыручылар саны артуы да күзәтелми. Эпидемия бер чамада тора, грипп белән авыручылар саны элеккечә – 89 кеше.

– Кискен тын юллары инфекциясе авыруын, гриппны кисәтү өчен Казанда бөтен чаралар да күрелә. Казанның медицина идарәсе җитәкчесе урынбасары Гөлсинә Хуҗиева аңлатуынча, балаларны кеше күп булган чараларга алып барырга киңәш ителми, медицина учреждениеләрендә маска кию кертелгән, табиблар көчәйтелгән режимда эшли. Әйтик, авырлы хатын-кызларда салкын тию, грипп билгеләре күзәтелә икән, аңа медицина ярдәме өйдә күрсәтеләчәк. Ничек кенә булмасын, һәрчак сакланырга, борын куышлыгын, кулларны юып торырга, бүлмәләрне җилләтергә, маска киеп йөрергә кирәклеген искәртә табиблар.

Эльвира МОЗАФФАР.

Татарстанның ашыгыч ярдәм хезмәте баш белгече Марина Воронцовага биш сорау

1. Нинди очракта ашыгыч ярдәм хезмәтен чакыртырга кирәк?

– Закон нигезендә, ашыгыч ярдәм барлык кешеләргә дә бушлай күрсәтелә. Шуңа да ашыгыч ярдәм хезмәте һәр чакыруга килә. Кискен сәбәпләр булмаганда да, табибларны чакыртучылар бар. Әйтик, 3 гыйнварда кабул ителгән 2 меңнән артык чакыруның бары 45 процентында гына чын-чынлап медицина ярдәме кирәк булуы ачыкланды. Температура югары булса да, ашыгыч ярдәм хезмәтен чакырталар. Мондый очракта сырхауханәгә барырга, участок табибына мөрәҗәгать итәргә дә була. Бары югары температура тын ала алмау кебек куркыныч хәлләр китереп чыгарганда гына, ашыгыч ярдәм хезмәтен чакыртсаң яхшырак. Күп очракта кеше гомеренә куркыныч янамый икән, без авыруны теркәлү урыны буенча сырхауханәләргә юллыйбыз.

2. Кеше гомеренә куркыныч яный торган авырумы, түгелме икәнен ничек ачыкларга?

– Чакыруны кабул итүче фельдшер моның өчен авыру турында мәгълүмат туплый. Сораулар бирә. Җаваплар аша авыруның хәле ни дәрәҗәдә икәнен белгели. Бик кискен очрак икән, ашыгыч ярдәм хезмәте, күп дигәндә, 20 минут эчендә килеп җитәргә тиеш, әгәр кеше гомеренә куркыныч янамый икән, табиблар ике сәгать дәвамында да килә ала.

3. Европа илләрендә ашыгыч ярдәм хезмәтен сәбәпсез чакырткан өчен штраф каралган. Бездә ничек?

– Бездә әлегә аңлату эшләре генә алып барыла. Авыруларны сырхауханәләрдә махсус бүлмәләрдә кабул итәләр, кичектергесез ярдәм күрсәтә торган кизү хастаханәләр бар. Кешенең мөмкинлеге, транспорты бар икән, ул үзе дә табибларга мөрәҗәгать итә ала.

4. Интернетта «ашыгыч ярдәм хезмәте түләүле булачак» дигән сүзләр таралды? Бу дөресме?

– Юк. Бу хакта былтыр да сөйләшүләр күп булды. Әмма әлегә ашыгыч ярдәм хезмәте түләүле булачагын раслаган бер генә карар, документ та юк. Дөрес, Казанда шәхси түләүле медицина ярдәме күрсәтә торган хезмәтләр бар. Кешегә сайлау мөмкинлеге тудырылган.

5. Ашыгыч ярдәм хезмәтенең бер чакыруга баруы дәүләткә ничә сумга төшә?

– Казанда тәүлек буе эшли торган 80 ашыгыч ярдәм хезмәте санала. Шул исәптән 11 ашыгыч ярдәм хезмәте балалар өчен махсуслашкан. Дәүләт гарантиясе программасы буенча, ашыгыч ярдәм хезмәтенең бер чакыруга баруы уртача 2300 сумга төшә.

«Түрәләрне кешелексез дип уйламагыз»

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан һәм Чаллыда өлешкә кереп торак төзелешендә катнашучыларның инициатив төркеме белән узган очрашуда шулай дип белдерде. Республика хөкүмәте йортында уткәрелгән киңәшмәгә Чаллы шәһәре мэры Наил Мәһдиев белән Казан шәһәре җитәкчесе Илсур Метшин да чакырылган иде, дип яза «Бизнес-онлайн».

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Наил Мәһдиев үзенең чыгышында билгеләп узганча, 2015 елда Чаллыда «Фон», «Свей» компанияләреннән зыян күргән 939 кеше теркәлгән. Соңгы ике елда 583 гаиләнең проблемасы хәл ителгән. Августта – 307, ноябрьдә 113 гаилә фатирлы булган. Тагын 356 өлешләп фатир алучының мәсьәләсен хәл итәсе бар. 65/10 торак йортыннан – 100 кеше; 65/06 йортыннан – 93; 65/03 йортыннан – 163. Наил Мәһдиев әлеге уңайдан Татарстан хөкүмәтеннән ярдәм сорады. Рөстәм Миңнехановның 2017 елда өлешләп фатир алучыларның күпмесенең мәсьәләсе хәл ителү турындагы соравына җавап биреп, Наил Мәһдиев, барысы да конкурс идарәчеләренә бәйле, диде.

Казанда исә вазгыять катлаулырак. «Фон» компаниясенең төзелеп бетмәгән – 17, «Свей»ның 5 йорты бар. Илсур Метшин хәбәр иткәнчә, 2016 елда Казанда биш торак йорт сафка бастырылган. Бу «Симфония» комплексының 2нче йорты, Урманче урамындагы 6нчы йорт (2,3 секцияләре), Баруди урамындагы 4нче, Бехтерев урамындагы 3нче йортлар һәм Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы торак комплексының 1нче йортының 1нче секциясе. Тагын ике йортны куллануга тапшыру көтелә. Шулай ук ул «Свей», «Фон» компанияләренең Казандагы төзелеп бетмәгән торак объектлары (Әмирхан, Четаев, Достоевский, академик Губкин, Павлюхин, Фучик, Нокса авышлыгы урамнарында) турында хәбәр итте.

Илсур Метшин Татарстан Президентына проблемалы йортларга инженерлык коммуникацияләрен китерүне челтәр компанияләренең инвестицион программаларына кертүне сорады. Әлеге утенечне өлешләп фатир алучыларның вәкилләре дә җиткерде. Алар Рөстәм Миңнехановка үзләрен борчыган сорауларын бирә алды. Сораулар күбесенчә йортларның тапшыру вакыты һәм төзелешне дәвам итүгә акча табу юлларына кагылды.

– Без түрәләрне кешелексез дип уйламагыз. Сезнең шундый катлаулы хәлдә калуыгыз мине дә борчый, – диде Президент аларга. – Барлык йортлар буенча, чыннан да, зур эш алып барыла, мин атна саен мәгълүматлар алып торам. Әйдәгез, алга таба барыйк, ярдәм итәр өчен бөтен мөмкинлекләрне дә кулланыйк. Бигрәк тә Казандагыларга авыр. Чаллы буенча 2017 елда без бу мәсьәләгә нокта куя алачакбыз.

Киләсе очрашуны ул җәйгә таба уткәрергә вәгъдә итте.

Фәрит Мөхәммәтшин:
«Безгә ышаныч зур»

Мәскәүдә узган «Бердәм Россия» партиясенең XVI съездында партиянең Югары советы һәм Генераль советына әгъзалар сайлау төгәлләнде. «Бердәм Россия»нең Татарстан төбәк бүлеге матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, Рөстәм Миңнеханов янә партиянең Югары советы әгъзасы итеп сайланды.

Татарстанның Дәүләт Советы рәисе, «Бердәм Россия»нең Татарстан төбәк бүлеге сәркатибе Фәрит Мөхәммәтшин, Казан мэры Илсур Метшин, Россия Дәүләт Думасы депутатлары Айрат Хәйрулин, Илдар Гыйльметдинов һәм Александр Сидякин Генераль совет әгъзалары итеп сайланды.

– Партиянең Татарстан төбәк бүлеге сәркатибе буларак, мине Генераль совет президиумына сайлап, ышаныч күрсәтелде. Миңа калса, бу безнең барлык дәрәҗәдәге сайлаулардагы уңышлы эшчәнлегебез нәтиҗәсе. Бу безнең партия оешмасының үз урынын табуын, куәтләнә баруын раслый, – дип белдерде Фәрит Мөхәммәтшин.

«Бердәм Россия»нең Генераль советында җитди ротация булуын да әйтеп китәргә кирәк. 170 әгъзаның 100е – яңалар.

Максат – гаиләләрне саклау

«Татар-информ» агентлыгы хәбәр итүенчә, Россия парламентының пленар утырышында депутатлар Татарстан Дәүләт Советы Россия Гаилә һәм Гражданлык кодексына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдим иткән закон проектын караган.

Әлеге закон проекты баласыз гаиләләргә ЗАГС аша аерылышу вакытын бер айдан өч айга кадәр арттыруны күздә тота. Балалы гаиләләрне суд аша аеру, ә ир яки хатын аерылышырга риза булмаганда, алты ай көтәргә мөмкин булуы тәкъдим ителә. Шулай ук закон проекты ике як та катнашмыйча читтән торып аерылышуларны да тыя. Татарстанның Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов белдерүенчә, Татарстан, әлеге закон проекты белән, Россиядә аерылышуларны киметүне максат итеп куя.

– ЗАГС аерылышырга теләгән гаиләләр белән эшләргә тиеш. Андый гаиләләргә психолог, консультантлар ярдәме күрсәтергә кирәк, – ди депутат.

Россия Дәүләт Думасының Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре буенча комитет рәисе Татьяна Плетнева Татарстан закон проектына катгый рәвештә каршы чыккан. «Мөселман төбәкләрендә аерылышулар саны иң азы», – дип тә әйткән ул. «Бердәм Россия», «Гадел Россия» фракцияләре дә бу закон проектына тәләктәшлек күрсәтмәгән. Пленар утырышта 450 депутаттан 423е катнашып, тавыш бирү нәтиҗәләре буенча закон проекты кире кагылган.

Россиядә уртача пенсия күләме 13 620 сум булачак

Быел Россиядә уртача пенсия күләме 13 620 сумны тәшкил итәчәк, дип хәбәр итә «Татар-информ», ТАССка сылтама белән. Россия вице-премьеры Ольга Голодец белдерүенчә, пенсия күләме пенсионерның яшәү минимумыннан якынча 60 процентка артыграк булачак.

Ольга Голодец, Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының бюджет турындагы канун нигезендә, пенсиягә 1 апрельдән булачак индексациягә кадәрге норматив акт әзерләвен җиткерде.

Искәртеп үтик, алдан Россия хезмәт һәм социаль яклау министры Максим Топилин, якындагы өч елда Россиядә пенсияләрнең реаль күләме кимүе котылгысыз, дип белдергән иде.

Бочковларның унөченче балалары туды

Республика клиника хастаханәсенең перинаталь үзәгендә күп балалы Бочковлар гаиләсендә кыз бала – Аврора туды. Бу – гаиләдәге унөченче бала: Аврораның ике абыйсы һәм ун апасы бар. Сабыйның авырлыгы – 4 кг 30 грамм. Бочковлар 24 ел бергә бәхетле тормыш кичерәләр, дип хәбәр итә Казан мэриясе сайты. Узган елның апрелендә аларның зур гаиләсе Әлмәттән Казанга күченде. Евгений Николаевич һәм Ольга Ивановна унөч баланың әти-әнисе генә түгел, әби һәм бабай да әле.

«Бу хәл тагын кабатланса, фаҗига булачак»

sntat.ru

– 2016 ел мал табиблары өчен җиңелләрдән булмады. Чөнки моңа кадәр имин булып килгән Татарстанда дуңгызларның Африка чумасы буенча начар очрак теркәлде. Бу хәл Нурлат районының Сосновка авылында булды. Нәтиҗәдә 426 баш дуңгызны юк итәргә туры килде. Бу, әлбәттә, Татарстан өчен зур «кара тап». Хәзерге вакытта да республикага куркыныч яный, әгәр без быел профилактика чаралары күрмәсәк, хәл тагын да катлаулыланырга мөмкин. Кызганыч, инфекция чыганагы билгеле түгел. Шулай да без монда кеше факторы (дуңгызларны имин булмаган төбәктән сатып алу) роль уйнагандыр, дип уйлыйбыз, – диде кичә Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында узган еллык киңәшмә барышында Татарстанның Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе Алмаз Хисаметдинов.

Саклану чаралары дигәндә, Алмаз Хисаметдинов та, Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсенең җитәкчесе Нурислам Хәбипов та үз хуҗалыкларында дуңгыз асраучы кешеләргә хайваннарны ишегалларында һәм урамнарда йөртү катгый тыелуы турында кат-кат искәртте. Җаваплы кешеләр бу хакта халык арасында аңлату эшләре алып барырга тиеш, ди алар. Дөрес, Африка чумасын профилактикалау максатыннан, 375 тикшерү уздырылган. Нәтиҗәдә 146 административ хокук бозу очрагы ачыкланган.

Африка чумасыннан тыш, терлекләрнең тормышына куркыныч яный торган башка авырулар да бар. Нодурлянка авыруы Татарстан белән чиктәш Самара өлкәсендә ачыкланган инде. Бу авыру Африка чумасына караганда да куркынычрак, ди белгечләр. Чөнки республикада бер миллионнан артык мөгезле эре терлек исәпләнә. Хәлне катлауландыручы тагын бер мәсьәлә – нодурлянкага каршы профилактика чаралары һәм авыруны дәвалау ысуллары да юк.

Мал табибларын һәм җитәкчеләрне борчый торган авырулар арасында туберкулез белән лейкоз да бар. Узган ел лейкоз белән авыру очракларын 2,5 процентка гына киметеп булган. Шуңа күрә быел әлеге мәсьәләләрдә тагын да ныграк тырышып эшләү бурычы куелды.

Россельхознадзор җитәкчесе урынбасары Светлана Алексеева әйтүенчә, Татарстанның авыл хуҗалыгы үсештә. Бу бик файдалы һәм керемле өлкә. Әмма ул аеруча игътибар таләп итүче проблемалар да булуы турында искәртте. Сүз әлеге дә баягы авырулар хакында иде.

– Туберкулез ул бик җитди авыру түгел бит, аны дәвалап була. Котыру чире буенча да максатчанрак эшләргә мөмкин. Хәзерге вакытта Россиядә кош авырулары буенча хәл катлаулы. Бу – кошларның баш санын югалтуга гына кагылмый, ә кеше сәламәтлегенә дә куркыныч яный торган очрак. Шушы авырулардан саклану чаралары тиешле дәрәҗәдә күреләме соң? Шулай ук файдаланылмый яткан чәчүлек җирләрне тикшерүне дә арттырасы иде, – дип мөрәҗәгать итте ул.

Дөрес, проблемалар белән беррәттән, уңышларны да күрергә кирәк. Монда мал табибларының хезмәт хакларын арттыру да (бүгенге көндә аларның уртача хезмәт хакы 22 400 сумны тәшкил итә), аларны торак, машина белән тәэмин итү дә, шулай ук авылларда мобиль ветеринар пунктлары ачылуны да әйтергә кирәк. Республикадагы вазгыятьне яхшырту максатыннан, Казан дәүләт ветеринария академиясе белән бергәлектә, кече ветеринария белгечләренең белемен күтәрү курслары да оештырыла. Мондый укулар Татарстанның тугыз районында үткәрелде.

Бөтен дөнья икътисади кризис кичергәндә дә, безнең республика авыл хуҗалыгы өлкәсендә биш процент үсеш күрсәтте. Быел да күрсәткечләр моннан түбән булмас, дип өметләнәбез. Шунысы кызганыч, дуңгыз чумасы авыруы очрагы теркәлү безнең өчен бик начар булды. Ярый, бу юлы без аны җиңеп чыктык, әмма мондый хәл республикада тагын кабатланса, ул чын-чынлап фаҗига булачак. Аннан соң шунысын да әйтергә кирәк: туберкулез һәм Татарстан бергә була алмый! Лейкоз авыруы буенча да бөтен көчне туплап, малларны терелтергә тиешбез. Өч ел эчендә без савым сыерларын яңартып, авырулардан да котыла алабыз, – диде Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

Аның эше укол кадау гына түгел

Александра Крайнова кешеләргә ярдәм итәргә ярата. Шуңа да ул 9нчы сыйныфны тәмамлагач, шәфкать туташы булырга ниятли. Гаиләләрендә табиблар булмагангамы, әти-әниләре кызларының бу омтылышларын хуплый. Бүген ул инде Казан медицина көллиятенең IV курсында укый. 20 яшьлек кыз хәзер гаиләнең таянычы. Әби-бабасына укол ясаучы да, өйдәгеләргә иң беренче булып медицина ярдәме күрсәтүче дә ул. Бу елның октябрь аенда исә Александра Абу Даби шәһәрендә узачак «WorldSkills International» чемпионатында ил данын яклаячак.

sntat.ru

– Мин мәктәптә укыганда ук инде табиб булырга хыялландым. Биология белән химия бик җиңел бирелде, – диде Александра.

Сәләтле кызны көллияттә дә күреп алалар. Ул «WorldSkills» һөнәри осталык чемпионатының республика, Россия этапларын уза. 2016 елда, Швециядә Евроскиллс бәйгесендә V урынны яулап, «Профессиональлек өчен» дигән махсус медальгә лаек була. Мәктәптә бары француз телен генә укыган кыз ярышларда катнашу өчен җиде ай эчендә инглиз телен махсус өйрәнә.

– Үз эшемнең остасы буласым килә. Көллияттән соң югары белем алачакмын. Бәлки киләчәктә эшем эндокринология белән бәйле булыр, – диде Александра.

«WorldSkills» хәрәкәтенә ул очраклы гына кушыла. Икенче курста барлык имтиханнарын да «бишле»гә генә биргәч, аны чемпионатта катнашырга чакыралар. Тора-бара ул Россия җыелмасына эләгә, хәзер исә 2017 елның октябрендә узачак «WorldSkills International» бәйгесенә әзерләнә.

– Россия этабы белән Европа этабы аерыла. Россиядә синең эш белүеңне җентекләп тикшерәләр, ә Швейцариядә пациент белән ничек аралашуыңа күбрәк басым ясыйлар. Республикада чемпионатка әзерләүче укытучылар җитәрлек, ләкин дөнья аренасына чыгу өчен, Европа белгечләре белән дә эшләргә кирәк, – диде кыз.

Ярышта Александра – актер, авыруның диагнозын белергә, 40 минут эчендә аңа тиешле ярдәм күрсәтергә тиеш. Боларның барысын да ул авыру белән инглиз телендә аралашу нәтиҗәсендә ачыкларга тиеш. Медицина җиһазларын зарарсызландыру, ингалятор кую, җәрәхәтне бәйләү кебек эшләр дә аның өстендә.

Практик осталыкка ул Казанның 7нче хастаханәсендә өйрәнә. 2014 елда хастаханә – «WorldSkills» чемпионатының рәсми партнеры.

– Александра кебек белгечләр кирәк безгә. Хәзерге вакытта шәфкать туташы эшенә игътибар артты. Операцияне яхшы башкару гына аз, авыруны операциядән чыгара белергә дә, инфекция булдырмаска да кирәк бит әле. Шәфкать туташының эше укол кадау белән генә чикләнми, – диде 7нче хастаханә баш табибы урынбасары – бәйсез эксперт Луиза Гобәева.

Балаң өчен жаның тыныч булсын дисәң – ТҮЛӘ

1 февральдән Казан балалар бакчаларында 12 сәгатьлек төркемнәр бетерелә. Шәһәрдәге күпчелекне тәшкил иткән төркемнәр иртәнге сәгать 7.30дан 18.00гә кадәр эшли башлаячак. Бу – төркемнең эш сәгате төгәлләнгәч, бала урамда кала дигән сүз түгел, әлбәттә. Сабыйны алтыдан соң да балалар бакчасында калдырырга була. Тик моның өчен аена 300 сум түләргә туры киләчәк. Казан шәһәре Башкарма комитетының бу хактагы карары белән мәгариф идарәсе җитәкчесе Илсур Һадиуллин тулырак таныштырды.

Эльвира МОЗАФФАР

НИ ӨЧЕН?

Элек-электән балалар бакчаларында дежур группалар эшләде. Эштә тоткарланган әти-әниләр өчен бу бик уңайлы иде. Яңа карар нинди максаттан чыгып кабул ителгән соң? Илсур Һадиуллин аңлатуынча, бу балалар бакчасының чыгымнарын экономияләү түгел, беренче чиратта, ата-аналарның мәнфәгатьләрен күздә тотып уйланылган адым.

– Карар чыкканчы, мәсьәлә шактый өйрәнелде, тикшерелде, балалар бакчалары мөдирләре, ата-аналар белән сөйләшүләр алып барылды. Озак еллар дәвамында балалар бакчаларында 10,5 һәм 12 сәгатьлек төркемнәр эшләп килде. 10,5 сәгатьлек төркемнәрдә 48 меңгә якын бала тәрбияләнә. Бу – барлык балаларның 70 проценты дигән сүз. Ә 12 сәгатьлек төркемнәргә 20 меңнән артык бала йөри (30 процент.) Ни хикмәт, шушы 20 мең баланың кичке алтыдан соң балалар бакчасында калу мөмкинлеге булса да, моннан бары 1120се генә файдалана торган булган. Ә калган 19 меңгә якын баланы әти-әниләре сәгать биштә үк алганнар, – ди Илсур Һадиуллин.

Баланы төрле түгәрәкләргә, бассейнга алып барырга кирәк, башка сәбәпләр дә килеп чыгарга мөмкин. 12 сәгать эшли торган төркем өчен ата-ана 3 мең сумнан артык түләсә дә, аны баласын кичкә калдырырга мәҗбүрләп булмый. Шул ук вакытта кичке алтыдан соң да бакча буш тормый. Кичке сәгать җидегә кадәр эшли торган әлеге 12 сәгатьлек төркемнәргә 10 сәгать эшли торган төркемнәрдән балалар күчә. Алар менә өстәмә сәгатьләр өчен түләми. Казан буенча дежур төркемнәрдә бушлай шөгыльләнүче шундый 8590 бала ачыкланган. Шуңа да ата-аналар арасында аңлашылмаучанлык чыккан. Ни өчен берәү баласын иртә алып та күбрәк түли, ә икенче берәүләр сәгать җидедә генә килеп алса да, аңа түләү азрак исәпләнә. Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен Казан Башкарма комитетының мәгариф идарәсе балалар бакчаларына түләү механизмына үзгәрешләр кертергә булган да.

НИЧЕК ТҮЛӘРГӘ?

Дежур группада калган балалар өчен аена өстәмә 300 сум түләргә туры киләчәк. Ул кире компенсацияләнми. Түләү ике квитанция буенча киләчәк. Ә менә 10,5 сәгатьлек төркемнәрдә шөгыльләнүчеләр өчен бер генә квитанция тапшырылачак. Шунысы да бар, балалары 12 сәгатьлек төркемгә йөргән һәм 1 февральдән 10,5 сәгатьлеккә күчкән ата-аналарга түләү бәясе 290 сумга кимételәчәк. Шул рәвешле күпләр 1 гыйнвардан балалар бакчасына түләүләрнең 8 процентка артуын сизмәстә, мөгаен.

– Мин бу яңалыкны бик сөенеп кабул иттем. Без баланы гел сәгать бишенче яртыда алабыз, чөнки каратэ түгәрәгенә өлгерәсе бар. 12 сәгатьлек төркем безнең өчен отышлы түгел иде. Хәзер менә 10 сәгатьлеккә әйләнгәч, түләү дә кими. Барысы да гадел эшләнгән, – ди ата-аналарның берсе Фирая Габбазова.

КҮПМЕ КЕШЕ ЙӨРИЯЧӘК?

Бүген Казанда 2846 мәктәпкәчә яшьтәге учреждениедә 67796 бала шөгыльләнә. Казанда физик яктан мөмкинлеге чикле, төрле тайпылышлар булган балалар өчен 78 төркем эшли. Дөрес, ул группаларга бу яңалык кагылмый. Алар 12 сәгать эш режимын дәвам итәчәк. Сүз уңаеннан, анда йөрүче 1, 2нче группа инвалид балалар өчен түләүләр 100 процент күләмендә кире кайтарыла. «Бүген сораштырулар буенча ата-аналарның бары 14 проценты гына дежур группаларга мохтаҗ икәнен белдергән. Бу хакта килешү төзер вакыт җиткәч, бу сан тагын да кимер, дежур төркемнәрдә калучылар ун процент кына булыр, мөгаен», – дип фаразлый Илсур Һадиуллин.

ТӘРБИЯЧЕЛӘР НИШЛӘР?

Тәрбиячеләргә бу яңалык тәэсир итми калмас анысы. Бүген 157 тәрбиячененең эш ставкасы кыскартылуга эләгә. Әмма аларның күбесенә вазифа алыштырырга, башка белгечлеккә күчәргә тәкъдим итәчәкләр. Башка балалар бакчасына күчү мөмкинлеге дә бар, беркем дә эшсез калмаячак. Бары пенсия яшендәге тәрбиячеләрнең генә ставкалары 0,75кә калыр дип уйлыйлар. Ничек кенә булмасын, тәрбиячененең выслуга буенча пенсия алу өчен кирәкле стажлары өзелмәячәк. Бу балалар бакчалары мөдирләре белән килешенеп эшләнә.

Магаданда бензинга талон кертелгән

Россиянең үзәк массакүләм мәгълүмат чаралары 23 гыйнварда Магадан өлкәсенең Колыма шәһәрендә АИ-95 маркалы бензинның фәкать талонга гына сатылуы турында хәбәр таратты.

Төбәк хакимияте сайтына куелган аңлатмага караганда, шөбһәләнерлек җирлек юк. Магадан өлкәсенә нефть продуктлары ташый торган танкер ватылган. Шул сәбәпле, АИ-95 бензинын сату күләменә вакытлыча чикләү кертелгән. Башка нефть продуктларына кытлык күзәтелми. Колымада АИ-92 бензины – 45,03 сумга, АИ-95 бензины – 47,27 сумга, ә дизель ягулыгы 45 сум 80 тиенгә сатыла.

Россиядә АИ-95 бензинына иң арзан бәя Иваново белән Курган өлкәләрендә – 35,87 сум. Ярославль өлкәсендә – 36,09 сум, Чечня Республикасында 36 сум 12 тиен. Иң кыйммәт бәя – Чукотка автономияле округында, анда АИ-95 бензинының бер литры – 56 сум. Камчатка краенда – 45,68 сум, Сахалин өлкәсендә – 45,47 сум, Кырымда 41 сум 82 тиен.

Казанда 23 гыйнварда автомобильләргә ягулык салу станцияләрендә АИ-92 бензины бәяләре: «Татнефть» белән «Татнефтепродукт»та – 34,8 сум, «Лукойл»да – 35,2 сум, «Башнефть»тә – 34 сум 9 тиен. «Татнефть», «Башнефть» һәм «Лукойл» станцияләрендә АИ-95 бензины – 37,9 сум, «Татнефтепродукт»та 37 сум 78 тиен иде.

– Ерак Көнчыгышта берничә ел яшәдем. Анда транспорт элемтәсе кыенлыгы булгалый. Магаданда АИ-95 бензины кытлыгыннан бөтен ил күләмендәге «фаҗига» ясау һич кирәкми иде, минемчә. Автомобилемә АИ-95 бензинын гомумән дә салганым юк, гел АИ-92не кулланам. Татарстанда бензинга кытлык туар, дип уйламыйм. Өзеклек булса, әнә метрода яки троллейбуста йөреп торырмын. Электр уты бетмәс әле, – дип кул гына селтәде автоһәвәскәр Фарит Хәмидуллин бу уңайдан.

Дамир БӘДРИЕВ.

kazanfirst.ru

«Сулык янында патшалык ясап яшәргә телиләр»

Татарстанда 2016 ел Су саклау зоналары елы буларак үтте. Ел дәвамында башкарылган эш нәтиҗәләре, хәл ителгән проблемалар, киләчәккә планнар турында «Татар-информ» агентлыгы хәбәрчесенә Татар районара табигатьне саклау прокуроры Илсур ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ сөйләде.

– Илсур Ирекович, ел дәвамында нинди нәтиҗәләргә ирештегез? Проблема массакүләм төстә хәл ителде дип әйтеп буламы?

– Дөресен генә әйткәндә, без бу елга әзер булып кердек, чөнки эш элегрәк башланган иде, аны бары дәвам иттердек. Бездән еш кына, күпме киртә җимердегез, дип сорыйлар. Андый бурычны куздә тотмадык. Без, беренче чиратта, кешегә ничек эшләргә кирәк, ә ничек ярамый икәнлеген җиткерергә тырыштык.

Ел дәвамында халыкка сулыкларга төшүне чикләү белән бәйле 387 факт ачыкланды. 334 административ материал төзелде, 67 дәгъва гаризасы буенча 276 объект сүттерелде. Әйтергә кирәк, Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан да зур эш башкарыла. Хәзерге вакытта барлык вак елгалар буенча инвентаризация үтелде. Сулыкларга төшү буенча кайда чикләүләр бар – барысы да билгеле. Быел беренче квартал эчендә, кайсын милекчеләрнең үзләреннән сүттереп, кайсын судка җибәреп, квартал ахырына бу эшләрне бетерергә тиешбез.

– Аеруча киң яңгыраш алган фактларны мисал итеп китерсәгез иде.

– Мишә буенда берничә авылда тоташ коймалар белән тотылган урыннар бар иде. 2013 елда рейд нәтиҗәсендә эш башладык. Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы су саклау зоналарын кадастрга куйды. Аннары шул коймаларны сүтү буенча эшне алып бару мөмкинлекләре туды. Чөнки судта картографик кәгазьләр буенча корылманың су саклау зонасында урнашканын дәлилләп була башлады. Шуннан соң, 2014, 2015, 2016 елларда бу эшне дәвам иттек. Хәзерге вакытта Мишә елгасы буенча гына да судка кырыклап гариза язылган, йөзләгән административ материал бар.

Хәзерге вакытта чиста дип әйтерлек бер сулык та юк, шуңа күрә безнең эш нәтиҗәсендә сулар чистарырга тиеш. Суга иң күп пычракны су чистарту җайланмалары агыза. Казанда, Әлмәттә дә бар алар, 70-80нче елларда салынган, кубесе рәтләп эшләми, нинди пычрак керә, суга шул пычрак агып төшә. Быел су чистарту җайланмаларын карап чыктык. Бөтенесендә «суны чистартып агызырга» дигән суд карары бар. Мәсәлән, Питрәч районында күптән түгел генә җинаять эше кузгатылды. «Теплострой» дигән ферма су чистарту җайланмалары белән эшләп, суны чистартмыйча гына, Мишәгә агызган. Анда пычрак матдәләрнең ПДК, ягъни рөхсәт ителгән концентрация чигеннән 360 тапкырга күбрәк булуы ачыкланды, шул сәбәпле җинаять эше кузгатылды. Хәзерге вакытта, суд карары нигезендә, реконструкция эшләре алып барыла. Әлмәттә, Бөгелмәдә һәм күп кенә зур шәһәрләрдә дә шундый ук эшләр үткәрелә.

«Водоканал»ның ләм саклау җайланмаларын бетерү турында суд карары бар. Отары, Кукушкино янында урнашкан зур гына территориядә «Водоканал» пычранган ләмен ташлый иде. Халыктан бик күп шикаятьләр килде. Быелтыр чыккан суд карары нигезендә, бу ләм саклау җайланмалары бетерелергә тиеш. Быел 25 ноябрьдә суд карары үз көченә керде. Суд приставларына ул карарны җибәрдек. Хәзерге вакытта эш бара. Тиздән бу проблема чишелер дип ышанып калам.

– Илсур Ирекович, сезнең фикерегезчә, закон бозуларның сәбәбе нидә? Халыкка аңлату җитмиме? Әллә белеп торып, санга сукмыйлармы?

– Халыкка аңлату да җитми, кайберәүләр белеп тә эшли. Мунчасыннан ук суга сикереп булсын өчен, йортын суга терәп сала кеше. Шуңа күрә, дөресен әйткәндә, күбесе белеп эшли. Элек халык, киресенчә, су басудан куркып, судан ерак урнашырга тырышкан. Элекке йортларны карасак, су янындагылар бик аз. Хәзер модасы шундый: сулык янында биек киртә белән уратып алып, патшалык ясап яшәргә телиләр. Шуңа күрә без ачыклаган барлык фактлар белеп эшләнгән.

Шуны әйтәсе килә: безнең эш нәтиҗәсендә кеше аңлый, уйлана башлады. Элегрәк җаза бирергә, судка барырга туры килә иде. Хәзер тикшерү барышында ук законсыз корылма хуҗаларының күбесе, коймаларын сүтеп, су кырыйларын бушата.

– Шулай да халыкка кагыйдәләрне искәртеп үтсәгез иде.

– Су кырыеннан ярдан алып 20 метр буш урын булырга тиеш, аңардан бөтен кеше дә куллана ала. 20 метрдан узгач төзергә була, әмма бер шарт бар: төзелә торган урында су саклау җайланмалары булырга тиеш, ягъни өйдән, мунчадан суны аерым бер җирдән генә агызырга мөмкин. Алар елгага агып төшәргә тиеш түгел. Агыза калсагыз да, су чистарту җайланмалары булырга тиеш. Суга, шулай ук җиргә агулы химикатлар кертергә ярамый. Эшмәкәрләргә ягулык салу станцияләре төзү рөхсәт ителми.

Эш барышында пирслар күп очрады. Күп кеше үз белдеге белән куя да, аннары безгә бу мәсьәлә белән шөгыльләнергә туры килә. Пирсларга килгәндә, Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән судан файдалану буенча махсус килешү төзергә кирәк. Ул очракта пирслар да, причаллар да төзергә була.

– Законсыз корылмалар төзегән кешеләр нинди штрафка тартыла?

– Физик затларга 5 мең сумга кадәр штраф каралган, һәм алар шул коймаларны үзләре сүтәргә тиеш. Корылмаларны үзләре ишмәсә, суд карары нигезендә, приставлар ишәчәк. Аннары приставлар моңа сарыф ителгән акчаны үзләренә ала.

– Карьерлар, урманнар белән бәйле вазгыять ничегрәк?

– Карьерлар – безнең бәла инде ул. Бигрәк тә Универсиадә, спартакиада уздырганда күп кенә төзелеш эшләре башланды. Ә һәр төзелеш ком, таш сорый. Шуңа күрә бөтен тирәдә, бигрәк тә Казан тирәсендә казый башлаганнар иде. Дөрес итеп, лицензия нигезендә казучылар бар. Ә бар шундыйлар: киләләр дә, экскаватор куялар да, бер-ике төн эчендә зур-зур чокырлар казып китәләр. Аннары бөтен кеше шул чокырга чүп ташлый. Урманда, су кырыйларында да чокырлар бар бит хәзер. Нәтиҗәдә әкренләп эрозия башлана, ишелә башлый.

Хәзерге вакытта бу фактлар берәз кимеде. 20 җинаять эше кузгатылды, берничә суд карары бар. Без җинаять эше генә кузгатып калмыйбыз, табигатькә китергән зыянны исәплибез. Ә бу – йөзләгән миллион сумнар. Мәсәлән, Теләче районында зур карьер казылып, табигатькә китерелгән зыян 250 миллион сум күләмендә бәяләнде. Хәзер гаепле оешма шул сумманы түләргә тиеш, без җинаять эше белән генә туктап калмыйбыз. Ул аны киредән күмеп, рекультивация ясап, үләнчәчеп, агач утыртып, тәртипкә китерергә тиеш. Хәзерге вакытта тикшерү бара, әлегә җинаять эше кузгатылмаган.

Бөгелмәдә, Питрәчтә күптән түгел генә җинаять эше ачылды, Лаешта дүрт җинаять эше кузгатылды. Зыян суммасы 1,5 млн сумнан алып 250 млн сумга кадәр тәшкил итә. Лицензия нигезендә эшләүче оешмалар да бар. Алар лицензия өчен дә, салымнарны да түли. Әмма «кара» казучылар аларның клиентларын үзләренә юнәтеп, эшсез калдыра. Салым да түләнми дигән сүз, бюджетка да зур зыян салына.

Урман кисү, урман тирәсендә казу эшләре аркасында табигатькә килгән зыянны исәплибез. Урман буенча шундыйрак хәл: элеккедән калган сыйфатмы – урман безнеке, барабыз да кисәбез дип уйлыйлар. Кешенең психологиясен үзгәртергә кирәк. Чүпне урманда ук ташлап калдыручылар күп. Аннары үзләре ук зарланалар. Балыкка килде, мәсәлән, ашаган-эчкән әйберен ташлап калдыра да, икенче юлы килгәч, су буе пычрак дип гаҗәпләнә. Аны кем чистартырга тиеш соң? Махсус җыештырып йөрүче оешма юк, дәүләттән андый акча каралмаган.

Хәзерге вакытта законга күп кенә үзгәрешләр кертелергә тиеш. Тиздән төбәк операторы дигән төшенчә килеп чыгачак. Чүп-чар әйләнеше өчен ике региональ оператор җавап бирәчәк. Аларга бик зур өметләр баглыйбыз. Гәрчә федераль закон буенча Россиянең барлык төбәкләрендә дә региональ операторларны 2017 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертү планлаштырылган булса да, хәзерге вакытта башка субъектларда ике елга кичектерү, ягъни 2019 елдан кертү турында сүз бара. Чөнки ул законның үтәлеше өчен бик күп карарлар кабул итәргә кирәк. Ә алар әле кабул ителеп бетмәгән. Татарстанда чүп калдыклары белән эш итү буенча территориаль схема эшләнеп кабул ителде. Шуңа күрә бездә төбәк операторлары, Россиядә беренчеләрдән булып, быел ук үз вазифаларына керешер дип көтелә. Ике юридик зат бөтен полигоннар, чүп җыю, логистика буенча эш башкарачак, теләсә кайда барлыкка килгән чүп өемен контрольдә тотачак. Бу проектка бюджеттан акча соралмый. Региональ оператор полигоннар төзү буенча үзенең инвестиции проекты белән керергә тиеш. Чүпне сортларга аеру, җыю, автотранспорт буенча да чыгымнарны үз өстенә ала.

– Су саклау зоналары елы тәмамланса да, шул юнәлештә эш дәвам иттереләчәкме?

– 2017 ел Россиядә Экология елы дип игълан ителде. Бездән күргәннәрдерме, бәлки үрнәк алганнардыр. Шуңа күрә бу эшне туктатмыйбыз. 2016 елда су саклау зоналарына игътибар итсәк, быел бу сорауга комплекслы килербез. Эшлисе эшләр күп, планнар зурдан.

Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА,
«Татар-информ».



tatar-inform.ru

Сәнгать һәм чынбарлык

«Күрдеңме? Карадыңмы Калебнең «Яңа дулкын» шигъри спектаклен? Бу яшьләрдә бигрәк өмет юк бит! Бигрәк төшенкелеккә бирелгәннәр инде. Шигырь укырга элмәк күтәреп чыктылар...» Мин карамаган идем. Видеоязмасын җибәрделәр. Карадым. Рәхмәт!

Марат КӘБИРОВ

Сәхнә бераз яктыра төшүгә, анда шәүләләр шәйләнә. Кайсы баскан, кайсы утырган. Кызмы, егетме икәнен дә абайларлык түгел. Бераздан ак күлмәкле кыз бала чыга да шул шәүләләрнең берсен сәхнә алдындарак торган тумбочка янына алып килә һәм каядыр китеп югала. Бая гына сәхнә түрендәге урындыкта шәмнән ясалган сынга охшап утырган нәрсә хатын-кыз булган икән. Бик бетеренгән, бахыр, берәрсен җирләгән көнедер инде. Акылына да бераз зәгыйфьлек килгән бугай, тумбочка өстендәге телефонга үрелергәме-үрелмәскәме дигәндәй, бик икеләнеп өч-дүрт минут буе тартышып тора. Шок кичерә инде бу, бичара.

Бәлки, бу бик драматик күренеш булып, минем күздән яшь китерергә тиеш булгандыр, әмма мин кычкырып көлеп җибәрдем. Бүгенге заман яшьләренең инфантильлегенә пародия сыман тоелды. Мин аларны: «Үзаллы түгелләр, гел җитәкләп йөртергә кирәк. Үзләре хастаханәгә барып теш тә алдыра алмыйлар», – дип тиргәбрәк йөри идем. Монда да үзләре телефонга үрелер өчен дә биш минут буе икеләнеп торалар. Ужас!

Ниһаять, үрелде. Теге очыннан ягымлы тавыш ишетелде:

– Ышаныч телефоны. Исәнмесез. Тыңлыйм сезне.

Сәхнәдәге күренеш беркадәр аңлашылгандай тоелды. Подвал тусовкасы ич бу. Кайсыдыр дустың үлсә яки полициягә эләксә, шундыйрак күренеш була торган иде. Бары тик ышаныч телефоны гына юк. Шуңа күрә иң яшерен серләр дә шушы подвалдагы кешеләр арасында кала. Бүген аз гына башкачарак икән.

Ышаныч телефонына кыз үз халәтен сөйли:

– Акылның саташкан бер мәле,
Аңламыйм вакыйга агымын...

Ул үз кичерешләрен дусларына түгел, ә телефонга сөйли. Чынлап та хәле бик сөенерлек түгел икән шул бу кызыйның. Әнә ич «мин – таушалып беткән бер китап» дип моңая. Бераздан шигырьнең мәхәббәт турында булуы төсмерләнә. Егете ташлап киткәнме соң моны, үзе кызулык күрсәткән дә хәзер үкенәме... Һәрхәлдә, аның:

«Әрнерме йөрәгең
мин юктан?!.» –

дигәнен ишеткәч, күңел беркадәр урынына утыргандай була. Аллага шөкер, сугыш чыкмаган, дөнья бетми икән әле. Ә мәхәббәт проблемалары рәте булган кеше тирәсендә гел бөтерелеп йөри инде. Шуларны уйлап шатланыптыр, залдагы халык та сыек кына кул чабып куйды.

Бераздан теге телефон янына икенче хатын-кыз килде. Монысы тәвәккәлрәк булып чыкты, шундук номерны җыйды.

– Ышаныч телефоны. Исәнмесез. Тыңлыйм сезне.

Ул бик моңсу шигырен болай дип бетерде:

«Яланаяк канга баткан килеш,
Мин яңа сукмак салып килəм».

Бик ышандырмады никтер. Язу стиле дә, уку рәвеше дә, темасы да алдагы ахирәтеннән берничек тә аерылмый иде. Күрәсең, моның «яңа сукмагы» туры мәгънәдә булды.

Тагын берәү. Тагын шундыйрак хәл. Анысы:

«Мин – мескен.
Кайда да бер артык.
Муенга уйларым чорнала».

Тагын берәү:

«Башланмый өзелгән
бер тормыш...»

Бая «подвалдагы үсмерләр тусовкасы» дигән уй да юкка чыкты инде. «Нәрсә соң бу? Җыен бәхетсез хатын-кыз җыелган нинди урын?» дип уйлап кына куйган идем... сәхнә аз гына яктыра төште дә анда егетләр дә барлыгы шәйләнде.

Һәм менә иң көтелгән мизгел. Ниһаять, теге тумбочка янына егет кеше килде. Буй-сын соклангыч, йөз-кыяфәт тә аһ итәрлек. Хатын-кызлар мескенлегеннән генә торган бәхетсез дөньяга чын ир-егет кулы кирәк ич. Ни өчендер нәкъ менә шушы егет нәкъ менә шушы урында вакыйгалар агышын әйләндереп җибәрер сыман тоелды. Хәтта аның тумбочкага менеп чүгәләве дә әтәч менгән читәнгә, дип уйлатмады. Бу – аның югарылыгын билгеләү өчендер кебек иде. Ләкин могҗиза булмады. Шул ук зар, чарасызлык, мескенлек. Егет кеше елак хисле кызлардан бары тик тышкы кыяфәте белән генә аерыла иде. Язу стиле дә, уку рәвеше дә, хәтта мескен тавышы да – кызларныкы... Хәер, тегеләрен дә «кызлар» дип булмыйдыр әле. Хатын-кызга тартым җан ияләре дияргә кирәктер. Барысында да ниндидер төссезлек, сорылык, хәтта җенессезлек...

Һәм аларның мескенлеге сиңа да йога, баса башлый. Кара төсләр, мескен кешеләр, елак шигырьләр... Болар ялкыта башлый, мәңге бетмәс булып тоела. Үзләре шундый күп алар, үзләре шундый бертөрле. Үз мескенлегеннән зарланып йөргән бу җан ияләренә ачу килә башлый. Шул авыр хәленнән чыгу өчен, берсе бер хәрәкәт ясап карасачы! «Кем тудырды сезне?!» – дип уйлыйсың...

Һәм сәхнәдәге бу кавемнең үз балаларың белән чордаш булуы, үзеңнекеләрдә дә шундый ук инфантильлек чалымнары булу искә төшә. Пәрәннек ашап үскән буын ич инде бу, өф-өф итеп үстерелгән халык. Үз күңелләрендә казынулары, кечкенә җан яралары да чокый-чокый зурайтырга тырышулары аңлашыла. Яшьләре дә шундый ич – сыткыларын сытып та яра ясый торган чак.

Миңа, кырыкны узган кешегә, аларның мәхәббәт дип шулкадәр өзгәләнүләре көлке кебек. Ләкин алар бит мин түгел. Беренчедән, яшь кеше өчен мәхәббәт проблемасы – дөнья бетү һәм сугыш башлануга караганда да зуррак.

Икенчедән... Алар әле тормыш чынбарлыгы белән мәхәббәт биләмәсендә генә йөзгә-йөз очрашкан кешеләр. Сугыш күрмәгән алар, ачлык татымаган, өйсезлекнең ни икәнен белми. Алар өчен бүтән чынбарлык юк. Өсләре бөтен, тамаклары тук, акчалары бар – боларның барысын да алар үзләре түгел, ә әти-әниләре хәл итә. Әти-әниләре аларны тормыш чынбарлыгыннан саклап калырга тырыша. Кулларыннан килсә, әлбәттә, мәхәббәттән дә саклап калырлар иде. Тик бу мөмкин түгел.

Шуңа күрә бу үсмерләр өчен мәхәббәт – бердәнбер чынбарлык. Үзләрендә казыну – бердәнбер мөмкинлек, чөнки алар бер алманы бишкә бүләргә өйрәнмәгән. Болар үзләреннән ерак карый белми. Кечкенә чакларында ук хәстәрлекле әти-әниләре: «Син иң акыллысы, син иң матуры, син иң талантлысы, син, син, син...» – дип читкә төбәлгән карашларын балаларының үзләренә кадап куйганнар. Һәм кирәксезлек тойгысының да нигезендә шул ята. Боларның кемгәдер күренәсе, үзләренең барлыгын һәм әйбәтлеген күрсәтәсе килә, ләкин күрүче юк – барысы да фәкать үзен генә күрергә сәләтле. Һәм боларның мәхәббәт шигырьләре дә ярату объектына түгел, ә үзләренең кичерешләренә багышланган. Болар үзләрен сөйгән ярлары аша яраталар.

Тукайлар чорына караганда да аянычрак боларның хәле. Тукай: «Мин кояш булмак телим», – дисә, болар үзләренең нәрсә теләгәнен дә белми. Рухи көрчеккә килеп терәлгәннәр. Үзенә күрә бер заман, ахры.

Ләкин яктылыкка омтылыш бар. Бу әзләнү өметсезлек аша, газап аша, хәтта үлемгә тартылу аша уза. Һәм ул бар. Без барыбыз да ата-аналарыбызның безне җил-давылдан сакларга тырышып корган читлеген ватып тормышка аяк баскан кешеләр бит инде. Зарлана-сукрана, егыла-тора, яралана-дәвалана адәм булган нәрсәләр. Урамда нинди гасыр булса да, һәр чебеш үз йомыркасын үзе тишеп чыга. Бүгенге яшьләр дә шулай үз юлын, үз мәсләген үзләре табар.

Мин бу әсәрне режиссерның (Әминә Миндиярова) һәм «Калеб» ачкан яшь талантларның (Эльнар Байназаров, Ләйлә Хәбибуллина, Гөлүсә Шиһапова, Азат Миргаязов, Гөлзилә Гафурова, Гөлназ Газизова, Алсу Сәлахова, Гүзәл Закирова, Эльвира Рафикова) зур уңышы дип исәплим. Тамашаны музыкаль яктан бизәүче композиторлар – Эльмир Низамов, Ләйсән Абдуллина, Ильяс Камал, Динә Хәкимова, Алсу Сөнгатуллина, Миләүшә Хәйруллина. Бик авыр кабул ителә, авыр һәм тирән тәэсир калдыра торган үзенчәлекле спектакль тудыра алганнар. Шигырьнең бөтенләй башка яссылыкка чыгуы дип тә билгеләргә мөмкиндер әле.

Тукай шигырьләре спектакльдә ориентир буларак та кулланыла. Гомумән, монда һәртөрле символларга, иллюзияләргә урын мул бирелгән. Әсәр азагында кечкенә кызчыкның (ул фәрештә булып чыкты) кара бишмәт кесәсеннән кәнфит алып ашавы да бик кызык тоелды. Һәр нәрсәнең тәмен табып була дигән сыманрак. Моны узган гасырның алтмышынчы елларында ук инде шагыйрь Әнгам Атнабаев: «Авырлыкның матурлыгын җырлау», – дип бәяләгән иде. Бер карасаң, шигырьләр генә түгел, ә менә шул вак детальләр бөтен итә спектакльне. Шул детальләр ярдәмендә әсәр үзе дә шигырь дәрәҗәсенә күтәрелә.

Аның әле шундый бер соклангыч үзенчәлеге дә бар: моны бит спектакль дип түгел, ә чынбарлык, яшь шагыйрьләрнең чыгышы дип кабул итәсең. Махсус рәвештә шундый шигырьләрнең сайлануын, уку рәвешенең дә, костюмнарның да спектакльнең төп идеясенә хезмәт итүен аңлаган хәлдә! Менә шул рәвешле режиссер сәнгать белән чынбарлык чикләрен җуя алган.

Ә элмәк... Ул яшь шагыйрьнең шигырь укырга элмәк күтәреп чыгуы түгел бит, спектакльнең бер эпизоды гына... «Әлдермештән Әлмәндәр»не карагач, без: «Равил Шәрәфи бик начар икән, гел Шәүкәт Биктимировны үтерергә тырышты», – дип әйтмибез ич. Һәм әлеге язмада спектакль персонажларына карата әйтелгән сүзләр анда катнашучы яшь шагыйрьләргә кагылмый. Шундый хәлләр...

Төп нигезең сакланамы?

Флёра Тархановaның «Сагыш үрләде йөрәккә» исемле эссесын авторның үткәне хакында күбрәк белү теләге беләнрәк укырга керешкән идем, ләкин эш мин уйлаганча килеп чыкмады. Әсәрнең «сагышлы» исеменә игътибар итеп җиткермәгәнмен, күрәсең.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

«Язмышлар язылганда» китабының әлеге эссены эченә алган бүлеге дә «Ялгышлардан торган язмышлар» дип атала икән бит әле. Нинди ялгышлар да нинди сагышлы язмышлар икән соң монда? Ярар, китаптан укып белик. «Әти мәрхүм булгач, әни дә, ялгызы яши алмыйча, сеңлемә торырга китте. Шулай итеп, бала чакта бербөтен булып яшәгән балалар кайсы кая таралышып бетте. Олыгайган саен, аралар ерагайган саен, бала чактагы туганлык хисләре кими бара кебек тоела миңа. Туып-үскән йортта бергә туплап торучы кеше булмадымы, балалар шунда кайтып һәрдаим аралашып тормадымы, акрынлап бетә башлый икән ул якынлык… Шуларны тоеп, күңелем әрни, җаным сыкрый».

Җаннарың сыкрарлык та шул: тугыз бала үсеп, канат ныгытып, үзбашка яшәрлек белем, тормыш күнекмәсе алган Тархановлар йорты буп-буш икән хәзер. Әдибә «Капка» исемле поэмасында да әлеге «бушлык»ка әйләнеп кайта. Әсәр мондый юллар белән тәмамлана:

Түзалмадым:
ятим өебезнең
Инде кыйшык
капкасыннан кереп,
Баскычына ятып
еладым.

Хуҗалары таралып бетү сәбәпле карауччысыз калган, шуңа тузып бара торган йортлар һәр авылда бардыр, нигә бу күренеш Флёра ханым Тархановaның гына күңелен әрнетә дә аны төрле формада кайта-кайта язарга мәҗбүр итә соң әле? Эш шундадыр, мөгаен, тугыз бала шау-гөр килеп яшәгән, һәркайсы төрле музыка коралларында уйнаган, җырлаган-биегән гаиләнең кинәт таралып, ата йортын ятим калдыруы бигрәкләр дә җан сыкраткыч булып тоеладыр аңа. Бер үк йортта ике чор тормышының аермасы коточкыч зур бит. Ике-өч кенә балалы гаиләнең үз йортын шундый хәлгә калдыруы да бик күңелле түгел әле. Тугыз баланың берсе йортны саклап, шунда гаилә корып яшәсә, бүтәннәргә дә кайтып-килеп йөрергә, туганлык хисләрен киметмәскә әйбәт буласы да бит, әмма ялгышлы язмышларны кабаттан язу мөмкин түгел шул.

Шуны уйлыйм әле, өч ел элек арабыздан киткән авылыбызның ил агасы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган укытучысы, Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы Бакый Зыятдинов исән булып, Флёра ханымның бу әсәрләрен укыса, ни дияр иде икән? Ул да бит ата йортын, төп нигезне саклау кирәклеген, моның өчен бигрәк тә гаиләдәге кече улның җаваплы булуын гомере буе язып һәм сөйләп килде. Әйбәт нәтиҗәсе әнә үз гаиләсендә. Әйе, Мәдинә һәм Бакый Зыятдиновларның ике кызы тормышка чыгып Казанга күчкәч, бердәнбер улларын да шәһәр тартмый калмагандыр, ә ул ата йортын саклап, гаиләсе белән матур гына яшәп ята. Әнисе дә үз янында, туганнарына да кайтып йөрер урын бар. Йортларын Бакый абый салдырганнан да зурайттылар әле.

Авылыбызда моңа охшаш мисаллар да аз түгел, шул ук вакытта кешеләре исән килеш юкка чыккан йорт урыннары да, бушап калган өйләр дә очраштыргалап тора. Авылның бер очыннан гына карый башласак та, шактый гыйбрәтле язмышларга юлыгачакбыз. Менә борынгы Себер юлы буйлап көнчыгыш яктан кергәндә беренче йорт Зөлфия апаларныкы иде. Ире Гыйльмулла абый сугыштан кайтмаган. Ике кызы ике якка тормышка чыкканнан соң, Зөлфия апа улы Зиннур һәм аның хатыны белән яшәде. Башта яман чирдән Зиннур абый, бераздан, картаеп, Зөлфия апа мәңгелеккә күчте, киленнәре икесен дә тәрбия кылды һәм әйбәтләп озатты. Аңа бу йортны саклап яшәргә дә яшәргә иде дә бит, Зөлфия апаның бер кызына өй сатып акча эшләргә кирәк булып чыкты шул. Ә баласы да булмаган килен артыкка әйләнде. Сатылган йортны сүтеп алдылар, инде урыны да беленми. Болай эшләүнең зур сәбәбе булгандыр анысы, машина алу өчен, улы акча таләп иткәндер. Оныкка аңа әллә кайдагы әби өенең исән торуы нәрсәгә, анда кайтып баш иясе юк бит. Йортны саткан кыз гына, балачак эзләрен сагынып бер кайтыйм дисә, капка ачып керер урыны юк менә. Сагыштан ятып еларга баскычы, чирәмле ишегалды да калмады хәтта. Кайтасы килдер анысы, олыгайган саен, кеше җаны-күңеле белән балачак эзләренә тартыла бит.

Авылның «Себер юлы тарихы» музеенда Карадуганның 1888 елгы планы бар. Зөлфия апалар йорт урыныннан узып саный барсак, ул чактагы ничә генә хуҗалыкның бүген яшәгән дәвамчыларын таный алырбыз икән? Күп түгел алар. Байтак гаиләләрне, эзләре дә калмаслык итеп, ачлык һәм сугыш еллары юкка чыгарган, Сталин чорының дәһшәтле 58нче маддәсе таркаткан. Ләкин бөтен сәбәп авыр елларда гына да түгел. Авыл тормышы ярыйсы гына көйләнә барган бу заманда да күп яшьләрне шәһәр тарта. Бигрәк тә кызларны кала кызыктыра. Кемдер уйлаганча, авылда кияү тапмаганнан гына китми ул. Кайберләре авыл егетенә кияүгә чыкканнан соң да, китәр җае булса, ирен шәһәргә кыстый. Ә ул ир ата йортын сакларга, әнисен дә үз янында яшәтергә тиешле кече ул була.

Аннары, «төп нигез» дигән төшенчәнең үзендә дә шактый гына шартлылык бар бугай. Әйтик, гаиләнең бер улы шул ук авылда башка чыгып, йорт җиткереп, шунда яши, ә төп нигездә яшәп калучылар бераздан кайсы кая таралыша, йорт бетә, бушап калган урынга бүтәннәр өй сала. Мондый очракта әлеге улны гаиләнең төп йортын саклаган дип буламы, әллә юкмы? Авылларның бөтен тормышы менә шундый хәрәкәттә икән бит, без аны сизмибез генә. Теге планны Карадуганның хәзергесе белән чагыштырып карасак, пландагы сиксәннән артык нигезнең нибары берсендә – Габделнасыйр Әхмәдиев нигезендә – шул нәселнең турыдан-туры дәвамчылары яшәгәнен күрербез. Ә бит сиксән биш нигезнең калган сиксән дүрте дә тулысынча корып бетмәгән. Әхмәдиев Мәҗит нәселеннән – дүрт, Әхмәтҗанов Шакирҗан һәм Таһиров Габделкәрим нәселләреннән бишәр гаилә биредә үк үз йортлары белән яшәп яталар. Ул чактагы элгәрләренең «гомерен» берәр-икешәр гаилә булып дәвам иттерүчеләр тагын да күп, ләкин берсенең дә йорты теге пландагы төп нигезендә түгел. Төп нигезләрен түгел, авылны саклаганнар алар. Әйе, сакламаучылар да байтак шул. Әнә бертуган Фәйзуллиннар 1888 елда өчесе өч йорт тотканнар, хәзер Фәйзуллин-Галиуллиннар нәселеннән авылда беркем юк. Безне анда кем көтеп тора, дип, бер оныклары, Әлфия исемлесе, ераклардан сагынып кайтканда да күрше авылга туктый иде, инде ул да кайтмаска китте. Фоат атлы тагын бер оныклары Казаннан кайтып, зиратта әрвахлар рухына дога укып, авылда беркемгә күренмичә кире китә торган булган. Бәлки, күз яшьләре белән киткәндер.

Сабан туенда гына булса да бер кайтып, авылына, зиратына баш иеп, туганнары белән күрешеп һәм истәлекләр яңартып йөрергә киң күңелле бер йорты булу – авылдан киткәннәрнең һәммәсе өчен уртак хыялдыр бу. Әнә шундый кунакчыл йорт хуҗасы булу вазифасын үз өстенә алырга теләүчеләр генә күп түгел.

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,
Балтач районы,
Карадуган авылы.

Ниһаять, быел Казанда чыршыларны утильләштерү өчен махсус пункт ачылды. Узган ел әлеге тема буенча язма әзерләгәндә, без шәһәр хакимиятенә дә, Экология министрлыгына да: «Яңа ел чыршыларын кая тапшырыйк?» – дип мөрәҗәгать иткән идек. «Аның өчен махсус тапшыру пункты ачылмый», – дип җавапладылар безгә.

Казанда чыршы җыялар

Быел менә күптән көтелгән пункт ачылган, әмма соңгарак калып. Теләге булган һәркем быел Яңа ел бәйрәме өчен сатып алынган чыршы агачын, уенчыкларын салдырып, яңа ачылган пунктка алып килеп, контейнерга сала ала. Халыктан җыеп алынган барлык чыршыларны Югары Ослан районында урнашкан фермер хуҗалыгына алып китәчәкләр. Чыршыларны ылыслы ботаклар ашарга ярата торган кәҗәләргә азык итеп бирәчәкләр. Пункт гыйнвар ахырына кадәр Гадел Кутуй урамы, 160 адресы буенча тәүлек буе эшли, дип хәбәр итә Идел буе экология компаниясе матбугат хезмәте.

Югары Ослан районының Шеланга авылы фермеры Мурат Сиразин Швейцария кәҗәләре тота. Алар өчен чыршы ботаклары менә дигән витаминлы азык булачак, ди ул.

– Кыш көне сусыл чирәм юк, аны менә шул чыршы ботаклары белән алыштырып була. Чыршы кирәк дип урманга барып, кисеп кайтып булмый бит. Чыршыларны җыеп китереп бирсәләр, миңа да яхшы була. Былтыр ике «КамАЗ» машинасы китерделәр. Әмма ул халыктан җыелган түгел иде. Чыршыларын бәйрәмгә сатып бетерә алмаган эшкуарлар китерде. Складны бушатырга кирәк, чүплеккә илтсәң, акча түләргә кирәк, диделәр. Аларга да җай чыкты, минем кәҗәләр дә рәхәтләнде, – дип сөйләде безгә фермер.

«Бүре дә тук, кәҗә дә исән» була инде бу.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

ФГБОУ ВО «КАЗАНСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ АГРАРНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»
ОБЪЯВЛЯЕТ КОНКУРС НА ЗАМЕЩЕНИЕ ВАКАНТНЫХ ДОЛЖНОСТЕЙ ПРОФЕССОРСКО-ПРЕПОДАВАТЕЛЬСКОГО СОСТАВА
1. Доцентов кафедры:
– общее земледелие, защита растений и селекция – 1
– агрохимия и почвоведение – 1
Ученый совет агрономического факультета 16 марта 2017 года.
Срок подачи заявлений – один месяц со дня опубликования в газете.
АДРЕС: 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 65.

«Татарстан гүзәле – 2017» Зөлфия Шәрәфиева:

«Җиңүем Сабадан булуым белән бәйле түгел»

«Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә республиканың иң чибәр кызын билгеләделәр. «Татарстан гүзәле» республикакүләм матурлык һәм сәләт бәйгесе быел инде унтугызынчы тапкыр оештырыла.

Алисә САБИРОВА

Шамил Абдюшев фотосы

«Татарстан гүзәле» иҗтимагый оешмасы президенты Изольда Сахарова сүзләренчә, бәйгенең быелгысы «Татарстан гүзәле» тарихында революция ясады.

– Без традицияләргә тугры кешеләр, шуңа да тамырдан үзгәртә алмыйбыз. Дөрес, ел саен конкурс стиле үзгәрә. 2017 ел – революция чоры. Элек без кызларга нәзакәтле, йомшак образлар булдырырга тырышсак, бүгенге образлар тыйнаграк, кырысрак дисәм дә була. Чыгышларда кызыл, кара, ак төс өстенлек итте. Конкурсантларга таләпләр елдан-ел арта. Урамнан гына кереп җиңеп булмый. Кайбер кызлар, җиңүче таҗы кию өчен, берничә ел әзерләнә, – диде Изольда Сахарова.

Төрле сынаулар үтеп, финалга 30 кыз чыккан иде, алар да сәхнә түрендә озак тормады. Су коену костюмында чыгыш ясау күпләр өчен зур сынау булды. Бәйгенең «сорау-җавап» өлешенә бары ун кыз гына калды. Кызлар биредә чәчләре генә түгел, ә акыллары да озын икәнен дәлилләргә тырышты. Ни кызык, күбесе жор телле, үткен сүзле булып чыкты. Жюрида утырган Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса Сулима: «Исегезгә төшкән берәр шигырьне сөйләгез әле»,– дигәч, бары берничә кызның гына кулы күтәрелде. Конкурсант кыз Камилә Харисова исә сәхнәдән Тукайның «Пар ат» шигырен яңгыратты. Сәясәт, спорт, матурлык, хәтта авыл хуҗалыгы темаларына сораулар яңгырады. Баксаң, алар сыер да сава белә икән әле. Бер кыз җәйге ялларга әбиләренә кунакка кайткач үзләштергән бу эшне.

«Татарстан гүзәле – 2017» бәйгесендә «Казан гүзәле» исемә 20 яшьлек Камилә Харисова лаек булды. Камилә тумышы белән Чаллы кызы. Казан федераль университетында реклама һәм PR белгечлеге буенча белем ала. Шулай ук инглиз телен өйрәнә.

– Бу җиңүем киләчәктә булган планнарымны тамырдан үзгәртте. «Татарстан гүзәле» бәйгесендә инде дүртенче тапкыр катнашам. Бу юлы, бәйгегә килергәме-юкмы, дип озак уйладым. Үзегез аңлыйсыздыр, бик авыр, күп көч һәм үзеңә ышаныч сорый торган адым. Минем бу исемгә лаек икәнемне дәлиллисем килде. Ләкин башка кешеләр моңа төрлечә карады. Тәүге тапкыр бәйгедә 15 яшемдә катнаштым. Элек минем өчен конкурста беренче урында тышкы матурлык иде: озын, матур чәч, зифа буй җиңүгә китерә дип уйладым. Ләкин иң мөһиме холкыңны күрсәтү икән. Хәзер конкурска килгән 15 яшьлек кызларны күрәм дә үземне искә төшерәм. Аларны «Җебегән булмагыз!» – дип әрлим дә әле. «Татарстан гүзәле» ул конкурс кына түгел, ә тәрбия мәктәбе дә, – диде Камилә Харисова.

Камилә мода дөньясына кереп киткәнче алты ел театр мәктәбенә йөргән. Залда исә аның өчен әти-әнисе һәм бертуган энесе җан атып утырды. Камилә Тукай шигырен сөйләгәндә дә әнисе бик дулкынланып тыңлап торган иде.

– Нинди юл сайласалар да, балаларга ярдәм итәргә кирәк. Баласына ата-ана белем, тәрбия бирергә тиеш. Кызымның сәхнәдән «купальниктан» йөрүенә дә уңай карыйм. Элек-электән хатын-кызның тышкы кыяфәте матурлык кына түгел, ә кешелекнең мораль эталоны булган. Без Изольда Сахарованы да бик күптәннән беләбез, аңа ышанабыз, – диде Камиләнең әтисе Рөстәм Харисов.

– Туу белән Камиләнең күзләре бер айлык сабыйныкы кебек иде инде. Шул вакытта ук мин аның бу гади бала булмаячагын аңладым, – диде кызның әнисе Лузия Харисова.

Республикабызның иң чибәр кызы исә Байлар Сабасында яши булып чыкты. Зөлфия Шәрәфиева шулай ук Казан федераль университеты студенты. Ул – программист-математик. Хәзерге вакытта «Казан экспо» ширкәтендә эшли. Зөлфиягә – 22 яшь.

– Иң авыры соңгы минутка кадәр үзеңне кулда тоту иде. Минем өчен бүген әти-әнием, дусларым, төркемдәшләрем җан атып торды. Сәхнәгә аларның ярдәмен тоеп чыктым. Дулкынланган вакытта, гел алар утырган якка карадым. Җиңүем Сабадан булуым белән берничек тә бәйле түгел. 2015 елда бу бәйгедә бер катнашкан идем инде. Сабадан булган өчен генә таҗ кидертсәләр, мин инде ул вакытта ук «Татарстан гүзәле» исемен алыр идем, – дип елмайды Зөлфия Шәрәфиева.

«Дакар-2017» һәм «Africa Eco Race-2017» халыкара ралли-рейдларында Россия данын яклап җиңү яулап кайткан команданың 23 вәкилен Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады.

«КамАЗ-Мастер» булдыра

– Безнең хыял тормышка ашты. Әле кайчан гына «КамАЗ-Мастер» командасын Африкага, Латин Америкасына озатып җибәргән идек. Борчылдык, чөнки узышлар киеренке булды. Безнең команда чираттагы тапкыр дөнья күләмендә үзенең булдыра алуын раслады. Бу бөтен илебез һәм республикабыз, билгеле, Чаллы өчен зур горурлык, – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

«Дакар – 2017»дә катнашып, бәгги зачетында 3 нче урынны алган Равил Магановны да республика башлыгы игътибарсыз калдырмады.

– Безнең яшь автоузышчыбыз барлыкка килүе бик күңелле, ул үзен күрсәтә белде һәм шундый җитди имтиханда түзде, – диде ул.

Татарстан Президенты «КамАЗ-Мастер» командасы вәкилләренә республика бүләкләре тапшырды, дип яза «Татар-информ».

Үзенең җавап сүзендә «КамАЗ-Автоспорт» коммерциягә булмаган партнерлыгы директоры, команда җитәкчесе Владимир Чагин, нәкъ менә быел Татарстан Президентының рәхмәте кыйммәт, диде.

– Көндәшлек бик югары иде, ярыш сәгатьләр түгел, минутлар, секундлар өчен барды. Без булдыра алганның барысын да, кирәк чакта Сезнең, Рөстәм Нургалиевич, ышанычыны аклар өчен, хәтта булдырып булмаганын да эшләдек. Ноябрьдә Чаллыда безнең машиналарга тест уздырганда Сез, «КамАЗ» чемпион машина булырга сәләтле, дигән идегез. Сезнең сүзләрне без бик яхшы хәтерлибез, ә Президент фикере ул – үтәлергә тиешле әмер. Без Сезнең, заводыбыз җитәкчелегенең, җанатарларның ышанычын аклавыбыз белән бик бәхетле. Һәм шуны расладык: тулы приводлы «КамАЗ» йөк машиналары – юлсызлыкта иң җитезләре, – дип сөйләде Владимир Чагин.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

Бу санның тиражы – 1551. Гомуми тираж – 5687.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 667. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы